**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче**
**Яңа Сарайлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

21 ноябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

2023 елда елда Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Чернобыль атом электростанциясендә аварияне ликвидацияләүчеләр-чернобыльчеләр, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су челтәрләрен проектлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру

Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы <u>90</u> кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – <u>63</u> кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәлә 63 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы <u>0</u> кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.
2. «2021 елда яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлар һәм

Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Чернобыль атом электростанциясендә аварияне ликвидацияләүчеләр-чернобыльчеләр, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су челтәрләрен проектлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру

Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә,

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Фазылҗанов